| МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|
| **ПРИКАЗ** | | **БОЕРЫК** |
| 17.03.2021 | г.Казань | № 137 |

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2021 елның 7 апрелендә 7631 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2012 елның 25 июлендәге 592 номерлы боерыгы белән расланган Билгеләнгән квота чикләрендә инвалидларны эшкә алуга, тикшерүләр үткәрү, мәҗбүри үтәлергә тиешле күрсәтмәләр бирү һәм беркетмәләр тотыру хокукы белән, күзәтчелек һәм контрольлекне гамәлгә ашыру буенча дәүләт функцияләрен үтәү буенча Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында законнарның нигезләмәләрен тормышка ашыру максатларында б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Билгеләнгән квота чикләрендә инвалидларны эшкә алуга, тикшерүләр үткәрү, мәҗбүри үтәлергә тиешле күрсәтмәләр бирү һәм беркетмәләр тотыру хокукы белән, күзәтчелек һәм контрольлекне гамәлгә ашыру буенча дәүләт функцияләрен үтәү буенча Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы

административ регламентын раслау турында» 2012 елның 25 июлендәге 592 номерлы боерыгы белән (Татарстан Респуб-ликасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 11.01.2013 №5, 25.09.2014 №518, 02.06.2015 №366, 02.07.2016 №377, 02.05.2017 №269, 27.12.2018 №1150, 03.06.2019 №421 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Билгеләнгән квота чикләрендә инвалидларны эшкә алуга, тикшерүләр үткәрү, мәҗбүри үтәлергә тиешле күрсәтмәләр бирү һәм беркетмәләр тутыру хокукы белән, күзәтчелек һәм контрольлекне гамәлгә ашыру буенча дәүләт функцияләрен үтәү буенча Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы
Хезмәт, халыкны эш белән
тәэмин итү һәм социаль
яклау министрлыгының
2021 елның 17 мартындагы
137 номерлы боерыгы
белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Билгеләнгән квота чикләрендә инвалидларны эшкә алуга, тикшерүләр үткәрү, мәҗбүри үтәлергә тиешле күрсәтмәләр бирү һәм беркетмәләр тутыру хокукы белән, күзәтчелек һәм контрольлекне гамәлгә ашыру буенча дәүләт функцияләрен үтәү буенча Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы административ регламентын раслау турында» 2012 елның 25 июлендәге 592 номерлы боерыгы белән расланган Билгеләнгән квота чикләрендә инвалидларны эшкә алуга, тикшерүләр үткәрү, мәҗбүри үтәлергә тиешле күрсәтмәләр бирү һәм беркетмәләр тутыру хокукы белән, күзәтчелек һәм контрольлекне гамәлгә ашыру буенча дәүләт функцияләрен үтәү буенча Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

1.2 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бердәм тикшерүләр реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасына (алга таба – бердәм тикшерүләр реестры) тиешле мәгълүматны кертү Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Күзәтчелек һәм контроль түбәндәгеләргә нигезләнеп гамәлгә ашырыла:

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы (алга таба – Административ хокук бозулар турында РФ кодексы) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2002, №1, 1 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2002, №1, 3 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 1991 елның 19 апрелендәге 1032-1 номерлы Россия Федерациясе Законы (алга таба – 1032-1 номерлы Россия Федерациясе Законы) (Ведомости Съезда народных депутатов РСФСР и Верховного Совета РСФСР, 1991, №18, 565 статья, кертелгән үзгәреш-ләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә гражданнарны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 181-ФЗ

номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1995, №48, 4563 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 59-ФЗ номерлы Федераль закон)(Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, №19, 2060 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре турында һәм мәгълүмат яклау турында» 2006 елның 27 июлендәге 149-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, №31, 3448 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 294-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2008, №52, 6249 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – «Электрон имза турында» Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, №15, 2036 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре турында» 2014 елның 29 декабрендәге 473-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 473-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2015, №1, 26 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары һәм муниципаль контрольлек органнары тарафыннан юридик затларга һәм шәхси эшкуарларга планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планнарын әзерләү кагыйдәләрен раслау турында» 2010 елның 30 июнендәге 489 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 489 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, №28, 3706 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерүләрнең бердәм реестрын форма-лаштыру һәм алып бару кагыйдәләре турында» 2015 елның 28 апрелендәге 415 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең №415 карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2015, №19, 2825 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре резидентларына карата дәүләт контролен (күзәтчелеген), муни-ципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле органнар тарафыннан уздырыла торган уртак планлы тикшерүләр турында» 2015 елның 22 октябрендәге 1132 номерлы карары (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1132 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2015, №44, 6127 статья);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерүләр оештырганда һәм

үткәргәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнары тарафыннан документларга һәм (яисә) мәгълүматларга, шул исәптән электрон рәвештә дә, әлеге документлар һәм (яисә) мәгълүматлар белән эш итүче башка дәүләт органнарына, җирле үзидарә орган-нарына яисә дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмаларга рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрү һәм аларны түләүсез нигездә алу турында» 2016 елның 18 апрелендәге 323 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 323 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2016 №17, 2418 статья);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) аерым төрләрен оештырганда куркыныч-юнәлешле якын килүне куллану һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 17 августындагы 806 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2016, №35, 5326 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Зарури таләпләрне һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозуның ярамаганлыгы турында кисәтүләр төзү һәм җибәрү, юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан мондый кисәтүләргә ризасызлыклар бирү һәм аларны карап тикшерү, мондый кисәтүне үтәү турында хәбәр итү кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 10 февралендәге 166 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 166 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2017, №8, 1239 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең Тикшерүләрне оештырганда һәм үткәргәндә дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнары тара-фыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында шушы документлар һәм (яки) мәгълүматлар белән эш итүче бүтән дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнарына яки җирле үзидарә органнарына буй-сынучы оешмалардан сорала һәм алына торган документлар һәм (яки) мәгълүматлар исемлеген раслау турында 2016 елның 19 апрелендәге 724-р номерлы боерыгы (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2016, №18, 2647 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында»гы федераль закон нигез-ләмәләрен тормышка ашыру хакында» 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы боерыгы (алга таба – Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы) (Российская газета, 2009, 14 май, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Билгеләнгән квота чикләрендә инвалидларны эшкә алуга, тикшерүләр үткәрү, мәҗбүри үтәлергә тиешле күрсәтмәләр бирү һәм беркетмәләр тутыру хокукы белән, күзәт-челек һәм контрольлек дәүләт функциясенең федераль дәүләт стандартын раслау турында» 2013 елның 30 апрелендәге 181н номерлы

боерыгы (Российская газета, 2013, 14 август, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Россия Федерациясе территориясендә, Ерак Көнчыгыш федераль округы территориясеннән тыш, оештырылган алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентларына карата дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль органнар тара-фыннан планнан тыш тикшерүләр уздыруны килештерү тәртибен раслау турында» 2016 елның 19 декабрендәге 817 номерлы боерыгы (алга таба – Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 817 номерлы боерыгы) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2017, 21 март, басылып чыгу номеры: 0001201703210041);

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Медик-социаль экспертиза буенча дәүләт учреждениеләреннән бирелә торган инвалидны тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең хосусый программасын, инвалид баланы тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең хосусый программасын эшләү һәм гамәлгә ашыру тәртибен һәм аларның формаларын раслау турында» 2017 елның 13 июнендәге 486н номерлы боерыгы (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2017, 1 август, басылып чыгу номеры: 0001201708010058);

«Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (Республика Татарстан, 2003, 17 май, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» 2006 елның 19 июнендәге 39-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (Республика Татарстан, 2006, 27 июнь, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урын-нарын квоталау һәм резервлау турында» 2006 елның 24 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 60-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Республика Татарстан, 2006, 28 июль, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының территориаль органы турында бертип нигезләмә раслау турында» 2006 елның 3 апрелендәге 144 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, №14, 2006, 0365 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек башкаручы эш бирүчеләргә инвалидларны эшкә урнаштыру өчен хезмәт урыннарын квоталау тәртибе турында нигезләмә раслау хакында» 2007 елның 4 маендагы 170 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек башкаручы эш бирүчеләргә инвалидларны эшкә урнаштыру өчен хезмәт

урыннарын квоталау тәртибе турында нигезләмә (алга таба – 170 номерлы ТР МК карары, Нигезләмә) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2007, №19, 0673 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәсьәләләре» 2007 елның 15 августындагы 388 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2007, №33, 1178 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә тикшерүләр үткәрү, үтәү өчен мәҗбүри булган күрсәтмәләр бирү һәм беркетмәләр төзү хокукы белән инвалидларны билгеләнгән квота чикләрендә эшкә кабул итүне тикшерүдә тотуны һәм аңа күзәтчелек итүне оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2017 елның 30 ноябрендәге 924 номерлы карары (алга таба – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 924 номерлы карары) («Татарстан Республикасы законнары җыентыгы» журналы, 2017, №92, 3359 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республи-касында хәтәрлеккә юнәлдерелгән алым кулланыла торган төбәк дәүләт тикшерүе (күзәтчелеге) төрләре исемлеген раслау турында» 2018 елның 27 сентябрендәге 856 номерлы карары (алга таба – 2018 елның 27 сентябрендәге 856 номерлы ТР МК карары)(«Татарстан Республикасы законнары җыентыгы» журналы, 2018, №77, 2491 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлеген раслау турында» 2007 елның 12 ноябрендәге 346 номерлы боерыгы (алга таба – Министрлыкның 2007 елныд 12 ноябрендәге 346 номерлы боерыгы) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2007, №46, 1833 ст.атья).»;

1.12 пунктның алтынчы абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

2.15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.15. Юридик затка, шәхси эшкуарга планлы тикшерүләр алар эшчәнлегенә беркетелгән хәтәрлек категориясенә бәйле рәвештә үткәрелә.

Юридик затның, шәхси эшкуарның эшчәнлеген билгеле бер хәтәрлек категориясенә кертү ТР МКның 924 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә тикшерүләр үткәрү, үтәү өчен мәҗбүри булган күрсәтмәләр бирү һәм беркетмәләр төзү хокукы белән

инвалидларны билгеләнгән квота чикләрендә эшкә кабул итүне тикшерүдә тотуны һәм аңа күзәтчелек итүне оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибе нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

2.16 пункттагы өченче абзацы көчен югалткан дип танырга;

2.17 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.17. Юридик затка, шәхси эшкуарга карата планлы тикшерүне Планга кертү нигезе юридик зат, шәхси эшкуар эшчәнлегенә беркетелгән хәтәрлек категориясенә бәйле.

Юридик зат, шәхси эшкуар эшчәнлегенә беркетелгән хәтәрлек категориясенә бәйле рәвештә күзәтчелек һәм контроль кысаларында планлы тикшерү уздыру түбәндәге вакыт аралыгы белән гамәлгә ашырыла:

уртача хәтәрлек категориясе өчен – 4 елга бер тапкырдан ешрак түгел һәм 5 елга кимендә 1 мәртәбә;

уртача хәтәрлек категориясе өчен – 6 елга бер тапкырдан ешрак түгел һәм 8 елга кимендә 1 тапкыр.

Эшчәнлеге түбән дәрәҗәле хәтәрлек категориясенә кертелгән юридик затка, шәхси эшкуарга карата планлы тикшерү уздырылмый.»;

5.54 пунктта «Татарстан Республикасы йогынты актларының җыелма реестры» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында» сүзләрен төшереп калдырырга.